КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 30 декабрь г.Казань № 1293

2025 елда муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләр һәм (яки) әлеге дотацияләрне алыштыра торган физик затлар керемнәренә салымнан бүлеп алып калынган сумманың өстәмә нормативлары буенча керемнәр алучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен социаль-икътисадый үстерү һәм аларның муниципаль финансларын савыктыру буенча чаралар күздә тотылып төзелә торган килешүләр турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 138 статьясындагы 8 пункты, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^2$ статьясындагы 8 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан дотацияләр һәм (яки) әлеге дотацияләрне алыштыра торган физик затлар керемнәренә салымнан бүлеп алып калынган сумманың өстәмә нормативлары буенча керемнәр алучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле администрациясе башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) белән социаль-икътисадый үстерү һәм аларның муниципаль финансларын савыктыру буенча чаралар күздә тотылып төзелә торган килешүгә (алга таба – килешү) түбәндәгеләр тарафыннан кул куела дип билгеләргә:

2025 елда муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан дотация һәм (яки) әлеге дотацияне алыштыра торган физик затлар керемнәренә салымнан бүлеп алып калынган сумманың (алга таба – дотация) өстәмә нормативлары буенча керемнәр алучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле администрациясе башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) тарафыннан кул куела һәм 2025 елның 15 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертелә;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан 2025 елның 22 гыйнварыннан да соңга калмыйча.

2. Килешү, 2025 елның 15 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле администрациясе башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына 2025 елда дотация алудан рәсми рәвештә баш тарту кәгазе җибәрелгән очракта, төзелми дип билгеләргә.

3. Килешүдә түбәндәгеләр каралырга тиеш дип билгеләргә:

дотация алучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең кушымтада бирелгән исемлек буенча йөкләмәләре;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының дотация алучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле администрациясе башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) тарафыннан тапшырыла торган, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең килешүдән барлыкка килә торган йөкләмәләренә кагылышлы документларны карап тикшерү буенча һәм бу документларга бәяләмә әзерләү буенча йөкләмәләре.

4. Дотация алучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле администрация башлыгына (башкарма-боеру органы җитәкчесенә) 2026 елның 20 гыйнварына кадәр кушымтада каралган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге йөкләмәләренең үтәлеше турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына хисап җибәрергә.

5. Дотация алучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге тарафыннан түбәндәгеләрдә каралган йөкләмәләр үтәлмәгән өчен җаваплылык чаралары буларак түбәндәгеләр була дип билгеләргә:

а) кушымтаның 1 пунктындагы «в» пунктчасында, 3 пунктында – 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән расланган дотацияләр бүленешенә үзгәрешләр кертү юлы белән 2026 елга дотация күләмен 2026 елга каралган дотация күләменең 1 процентыннан артмаган, әмма 2025 ел өчен муниципаль район (шәһәр округы) бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисап мәгълүматы буенча муниципаль район (шәһәр округы) бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренең 1 процентыннан артмаган күләмдә киметү;

б) кушымтаның 2 пунктындагы «а» пунктчасында – 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән расланган дотацияләр бүленешенә үзгәрешләр кертү юлы белән 2026 елга дотация күләмен әлеге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге тарафыннан үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларның,

җирле үзидарәдәге сайлап куелган вазыйфаи затларның, контроль-хисап органы рәисенең, рәис урынбасарының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә тотыла торган бюджет ассигнованиеләре күләме әлеге максат өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән чыгымнарны формалаштыру нормативлары нигезендә исәпләп чыгарылган бюджет ассигнованиеләре күләменнән артып киткән, әмма 2026 елга каралган дотация күләменең 1 процентыннан артмаган һәм 2025 ел өчен муниципаль район (шәһәр округы) бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисап мәгълүматы буенча муниципаль район (шәһәр округы) бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренең 1 процентыннан артмаган күләмдә кимету;

в) кушымтаның 2 пунктындагы «д» пунктчасында – Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең чараларны тормышка ашыруга, муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны гамәлгә ашыруга һәм күчемсез мөлкәтне муниципаль милеккә сатып алуга бәйле чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына өстәмә финанс ярдәме күрсәтүне туктатып тору.

6. Дотация алучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге түбәндәгеләр өчен җаваплылыктан азат ителә дип билгеләргә:

2025 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге тарафыннан әлеге йөкләмәләрнең үтәлешенә комачаулый, җиңеп чыга алмый торган вакыйгалар (федераль характердагы гадәттән тыш хәлләр) барлыкка килгән очракта, кушымтаның 1 пунктындагы «в» пунктчасында һәм 2 пунктындагы «а» пунктчасында каралган йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән өчен;

2024 ел белән чагыштырганда 2025 елда тапшырылган Татарстан Республикасы вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына тапшырылган Татарстан Республикасы вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләрне бүлү методикасына үзгәреш кертү сәбәп булып торган әлеге арту чикләрендә субвенция күләмен арттыруга бәйле рәвештә әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре саны арттырылган очракта, кушымтаның 2 пунктындагы «в» пунктчасында каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен.

7. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

дотация алучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле администрациясе башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) тарафыннан 2025 елның 15 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына әлеге вазыйфаи зат тарафыннан кул куелган килешү кертелмәгән очракта, 2025 елга дотация күләме 2025 елга каралган дотациянең 10 проценты күләмендә «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган дотацияләр бүленешенә үзгәрешләр кертү юлы белән киметелә;

Дотация алучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле администрациясе башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) тарафыннан 2025 елның 15 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына

2025 елда дотация алудан рәсми баш тарту кәгазе җибәрелгән очракта, 2025 елга каралган дотация күләме «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган дотацияләр бүленешенә үзгәрешләр кертү юлы белән тулы күләмдә киметелә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 30 декабрь, 1293 нче
карарына кушымта

Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан дотация һәм (яки) әлеге дотацияне алыштыра торган, килешүгә кертелергә тиешле физик затлар керемнәренә салымнан бүлеп алып калынган сумманың өстәмә нормативлары буенча керемнәр алучы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеген социаль-икътисадый үстерү һәм аның муниципаль финансларын савыктыру буенча чаралар карала торган килешүгә кертелергә тиешле йөкләмәләре
исемлеге

1. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең дотациялелеге дәрәҗәсен киметүгә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәрен арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру буенча түбәндәгеләр карала торган йөкләмәләр:

а) 2025 елның 1 ноябренә кадәр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында» 2019 елның 22 июненнән 796 номерлы карары белән билгеләнгән Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган салым ташламаларының (салым буенча түбәнәйтелгән ставкаларның) нәтиҗәлелеген бәяләүне үткәрү;

б) 2025 елның 20 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган салым ташламаларының (түбәнәйтелгән салым ставкаларының) нәтиҗәлелеген бәяләү нәтиҗәләрен, шулай ук, әгәр салым ташламаларының (түбәнәйтелгән салым ставкаларының) нәтиҗәлелеген бәяләү нәтиҗәләре буенча нәтиҗәле булмаган салым ставкалары (түбәнәйтелгән салым ставкалары) ачыкланган булса, нәтиҗәле булмаган салым ставкаларын (түбәнәйтелгән салым ставкаларын) гамәлдән чыгару планын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертү;

в) чагыштырма шартларда 2024 ел өчен үтәлеш дәрәҗәсе белән чагыштырганда 2025 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең берләштерелгән бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре артуны тәэмин итү (процентта);

г) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле администрациясе башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) тарафыннан Россия Федерациясе бюджет законнары таләпләренә туры килү-килмәүгә бәяләмә бирү өчен түбәндәгеләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җибәрелү:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органына кертелгәнгә кадәр 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органы карарлары проектлары;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органына кертелгәнгә кадәр 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты турында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органы карары проекты.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына әлеге пунктчада күрсәтелгән муниципаль норматив хокукый актлар проектларын, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тәкъдимнәрен исәпкә алмыйча, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең тиешле вәкиллекле органына кертмәскә.

2. Бюджетны консолидацияләүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру буенча түбәндәгеләр карала торган йөкләмәләр:

а) соңгы өч хисап финанс елының икесе дәвамында бюджетында Татарстан Республикасы бюджет системасының башка бюджетларыннан дотацияләрнең (күрсәткечләрнең, шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең иң яхшы зурлыкларына ирешүгә ярдәм итү һәм (яки) бүләкләү һәм (яки) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең иң яхшы тәҗрибәләре өчен бүләкләү максатларында җирлек бюджетларга бирелгән дотацияләрнеияәпкә алмыйча) һәм (яки) бүлеп алып калынган сумманың өстәмә нормативлары буенча салым керемнәренең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә бүлеп алып калынган сумманың өстәмә нормативлары белән алыштырылган дотациянең исәп-хисап күләменнән (дотациянең исәп-хисап күләме өлешеннән) артмаган күләмдәге өлеше җирле бюджетның үз керемнәре күләменең 5 процентыннан артып киткән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларын үтәү;

б) муниципаль учреждениеләрнең вакытында түләнмәгән кредит бурычларын барлыкка килүне булдырмау;

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре санын арттыруны тәэмин итү, шулай ук җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары проектларын финанс органына килештерү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре санын арттыру, кирәк булган очракта, Россия Федерациясе дәүләт

хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары арасында вәкаләтләр бүлешү нәтиҗәсендә хезмәткәрләр санын арттыру турында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хокукый актлары проектларын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына килештерүгә җибәрүне тәэмин итүгә;

г) Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән дотацияләрне Татарстан Республикасы бюджетында каралган күләмнән артмаган күләмнәрдә керемнәр составына кертеп, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларын раслау;

д) Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына салым түләүләре буенча бурычларны кыскарту чараларын үткәрү, шул исәптән үткән елның шул ук чоры белән чагыштырганда һәр кварталның 1 нче көненә салым түләүләре буенча бурычлар (банкротлык процедурасында булган һәм ябыла торган салым түләүчеләрнең недоимкасыннан тыш) артуны булдырмау, салым түләнергә тиешле елдан соң килә торган елның 1 апреленә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары, муниципаль учреждениеләр һәм муниципаль унитар предприятиеләр хезмәткәрләре, физик затлар тарафыннан түләнергә тиешле салымнар буенча бурычларны тулысынча каплауны тәэмин итү;

е) муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан норматив финанслау принципларын үтәү;

ж) хезмәткәрләрнең тарификациясе буенча исәпләнгән күләмнән ким булмаган күләмдә хезмәт өчен түләү фондын планлаштыруны исәпкә алып, муниципаль бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан финанс-хуҗалык эшчәнлеге планнарын формалаштыру;

з) 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карар, 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына үзгәрешләр кертү турындагы карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштыру;

и) ай саен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетының үтәлеше турындагы хисапларны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштыру.

3. Муниципаль финанслар белән идарә итүнең сыйфатын яхшырту кысаларында чараларны гамәлгә ашыру буенча түбәндәгеләр карала торган йөкләмәләр:

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $92^{1}$ статьясында билгеләнгән җирле бюджет кытлыгының иң чик күрсәткеченә карата таләпләрне үтәү;

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 106 статьясында билгеләнгән муниципаль бурыч алуларның иң чик күләменә карата таләпләрне үтәү;

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән муниципаль бурыч күләменә карата таләпләрне үтәү;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карарда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганагы буларак каралган, Россия Федерациясе бюджет системасының башка

бюджетларыннан җәлеп итүгә планлаштырылган бюджет кредитлары Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бирү турында карар кабул ителгән бюджет кредитлары (җирле бюджетлар счетларындагы акчаны калган өлешен тулыландыруга бюджет кредитларыннан тыш) суммасыннан артыграк булмау;

һәр айның 1 нче көненә карата Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырыла торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең бурыч китабы мәгълүматы нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең бурыч йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән бурычы булмау.

4. Әлеге исемлектә каралган йөкләмәләр үтәлмәгән очракта (әлеге исемлекнең 1 пунктындагы «в» пунктчасында, 2 пунктындагы «а» һәм «д» пунктчасында, 3 пунктында каралган йөкләмәләрдән тыш) Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле администрациясе башлыгы (башкарма-боеру органы җитәкчесе) тарафыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының гамәлләре (гамәл кылмавы) әлеге йөкләмәләрне бозуга китергән вазыйфаи затларына карата дисциплинар җаваплылык чараларын куллану буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге йөкләмәсе.